**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ТАТАРСКО-САРАЛОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
422633,РТ, Лаишевский район, село
Татарские Саралы, ул.Татарстан, д.17
тел: 8-(84378) -4-77-49
факс: 8-(84378) -4-77-49

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАР САРАЛАНЫ АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422633, РТ, Лаеш районы, Татар
Сараланыавылы, Татарстан урамы, 17
нчейорт
тел: 8-(84378) -4-77-49
факс: 8-(84378) -4-77-49

---

**2024 елның 1 апреле** **160 номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Сараланы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 10 декабрендәге 121 номерлы Татар Сараланы авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татар Сараланы авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. **Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Сараланы авыл җирлеге Советы белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Сараланы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә**.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Н.Н.Исхаков**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль
районының «01» апрелендәге 160 номерлы
Татар Сараланы авыл җирлеге Советы
карарына кушымта

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Сараланы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 10 декабрендәге 121 номерлы Татар Сараланы авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

12 статьяның 3 абзацына түбәндәге сүзләрне өстәргә:

Территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә җирлекнең генераль планына, шәһәр округының генераль планына үзгәрешләр кертелгән очракта, иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.".

.